| | | |
|---|---|---|
| **РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**<br><br>**ГЛАВА<br>СТАРОАЛЬМЕТЬЕВСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>НУРЛАТСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА** | | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**<br><br>**НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ<br>ИСКЕ ӘЛМӘТ<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** Иске Әлмәт ав. **КАРАР**

«01»апрель 2024 ел № 4

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Әлмәт авыл җирлегенең Нариманов исемендәге поселогында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Иске Әлмәт авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 23 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Иске Әлмәт авыл җирлеге башлыгы

КАРАР ИТТЕ**:**

1. 2024 елның 11 апрелендә 13 сәгать 00 минутка түбәндәге адрес буенча: Лесная урамында урнашкан мәчет янында Татарстан Республикасы, Нурлат муниципаль районы, Иске Әлмәт авыл җирлеге Нариманов исемендәге поселокта яшәүчеләр өчен үзара салым кертү буенча гражданнар җыенын уздыруны билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Иске Әлмәт авыл җирлегендә халык җыены этапларын үткәрү һәм оештыру белән Иске Әлмәт авыл җирлеге башлыгы һәм Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Иске Әлмәт авыл җирлеге башкарма комитеты тәэмин итә.

3. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез элек расланган карарларда гражданнар җыенына чыгарылган мәсьәләгә үзгәрешләр кертүгә ризамы:

Нариманов исемендәге торак пунктта гражданнар җыены нәтиҗәләре турында карар.Нариманов. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Әлмәт авыл җирлегенең 15.11.2023 ел, № 7;

Нариманов исемендәге торак пунктта гражданнар җыены карары Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Әлмәт авыл җирлегенең Нариманов 15.11.2023 ел 8,

аны түбәндәге редакциядә раслап:

«Сез 2024 елда Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Әлмәт авыл җирлеге территориясендә яшәүче 1 гр инвалидлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның һәм тол хатыннарыннан тыш һәр балигъ булган кешедән 10 000 сум, үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы:

- Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Әлмәт авыл җирлегенең Нариманов исемендәге поселогы чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту ( юлларны тоту, вак таш сатып алу, юл япмасы профилен үзгәртеп, юл салу хезмәте өчен).

- Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Әлмәт авыл җирлегенең Нариманов исемендәге торак пункты чикләрендә юлларны карап тоту, грейдерлау буенча хезмәтләр һәм алга таба юл күтәрү өчен тыгыз нигез салу шул исәптән сезонлы карап тотуга);

- торак пункт территориясен төзекләндерү (Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Әлмәт авыл җирлегенең Нариманов исемендәге торак пункты территориясен төзекләндерү);

«РИЗА» «КАРШЫ».

4. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru., Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында района http://nurlat.tatarstan.ru, Иске Әлмәт авыл җирлегенең Иске Әлмәт авылы мәгълүмат стендларында гражданнар җыены этапларын үткәрү датасына 10 көннән дә соңга калмыйча бастырып чыгарырга (игълан итәргә).

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Иске Әлмәт авыл җирлеге башлыгы Р.Г. Хисамов